ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 04 » август 2023 ел № 671

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан өйдә укыту оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны һәм инвалид балаларны ике тапкыр түләүсез туклану, шул исәптән түләүсез ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге белән тәэмин итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясының 7, 7.1, 7.2 өлешләренә, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясының 6.1 өлешенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының 2023 елның 28 февралендәге 2351/23 номерлы хатын исәпкә алып, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны һәм инвалид балаларны ике тапкыр түләүсез туклану, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге белән тәэмин итү тәртибен расларга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә әлеге карар буенча финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
04 август 2023 ел, №671
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан өйдә укыту оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны һәм инвалид балаларны ике тапкыр түләүсез туклану, шул исәптән ике тапкыр түләүсез тукалануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге белән тәэмин итү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан өйдә укыту оештырылган инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7.2 өлешенә ярашлы рәвештә, эшләнде (алга таба-Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы - «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләре (алга таба - мәгариф учреждениеләре) тарафыннан өйдә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны һәм инвалид балаларны ике тапкыр түләүсез туклandыруны тәэмин итү шартларын, формасын һәм процедурасын регламентлый.

1.2. Гомуми белем бирү программаларын өйдә үзләштерүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм инвалид балаларга (алга таба-өйдә белем алучылар) ике тапкыр түләүсез туклану өчен компенсация бирү формасы - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм алар чикләрендә мәгариф учреждениесенә җиткерелгән өйдә белем алучыларны туклану белән тәэмин итү максатыннан ике тапкыр түләүсез туклану бәясенә тиң булган азык-төлек җыелмасы бирү яки аны акчалата компенсация белән алыштыру.

1.3. Мәгариф учреждениеләре тарафыннан өйдә белем алучыларга ике тапкыр түләүсез туклану оештыру буенча чараларны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләрне башкаруга) муниципаль биремне финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү рәвешендә башкарыла.

1.4. Ике тапкыр түләүсез туклану өйдә белем алучыларга белем алу процессы вакытында бирелә. Каникул вакытында азык-төлек бирү башкарылмый.

2. Өйдә белем алучыларга азык-төлек җыелмасы бирү яки аны акчалата компенсация белән алыштыру шартлары һәм процедурасы.

2.1. Белем бирү процессын гамәлгә ашыру чорында өйдә белем алучыларга азык-төлек җыелмасын бирүне оештыру мәгариф учреждениеләренә йөкләнә.

2.2. Өйдә белем алучылар өчен азык-төлек җыелмасының бәясе «Җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 8 апрелендәге 208 номерлы карары нигезендә, мәгариф учреждениеләрендә көндезге формада белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм тиешле яшь категориясендәге инвалид балалар өчен уку көнендә түләүсез ике тапкыр туклану бәясеннән һәм үткәрелгән дәресләрне исәпкә алу журналы буенча уку көннәре саныннан чыгып исәпләнә.

2.3. Мәгариф учреждениесе өйдә белем алучыны азык-төлек җыелмасы белән мәгариф учреждениесенең локаль акты белән билгеләнгән вакытка (әмма айга бер тапкырдан да сирәгрәк түгел) тәэмин итә яки акчалата компенсацияне күчерә.

2.4. Азык-төлек җыелмасына кертелгән азык-төлек ассортименты халыкның җәмәгать туклануын оештыруга гамәлдәге санитар-эпидемиологик һәм гигиена таләпләренә ярашлы рәвештә билгеләнә.

2.5. Өйдә белем алучы67ларны азык-төлек белән тәэмин итү хокукы мәгариф учреждениесе җитәкчесе тарафыннан өйдә белем алуны оештыру турында боерык акты чыккан көннән барлыкка килә.

2.6. Өйдә белем алучыларны азык-төлек җыелмасы белән тәэмин итү турындагы карар мәгариф учреждениесе тарафыннан агымдагы елның 1 сентябренә кадәр өйдә белем алучының ата-анасының (законлы вәкиленең) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада тәкъдим ителгән форма буенча ике тапкыр түләүсез туклану турындагы гаризасы нигезендә кабул ителә (алга таба-гариза) һәм мәгариф учреждениесенең боерык акты белән рәсмиләштерелә.

2.7. Уку елы дәвамында азык-төлек җыелмасы белән тәэмин итү хокукына ия булган өйдә белем алучыларны азык-төлек җыелмасы белән тәэмин итү турындагы карар мәгариф учреждениесе тарафыннан гариза нигезендә күрсәтелгән хокукны алган көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә һәм мәгариф учреждениесенең боерык акты белән рәсмиләштерелә.

Өйдә белем алучыларга азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру турындагы карар өйдә белем алучыга азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру турында ата-ананың (законлы вәкилнең) гаризасы кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә мәгариф учреждениесе тарафыннан тәкъдим ителгән формага (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта) ярашлы рәвештә кабул ителә һәм мәгариф учреждениесенең боерык акты белән рәсмиләштерелә. Акчалата компенсация түләү әлеге Тәртипнең 2.16 пунктында билгеләнгән срокта, өйдә белем алучыга ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру турында гариза биргән айдан соң башкарыла.

2.8. Әгәр өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) исеменнән вәкаләтле вәкил эш итә икән, гаризага өстәмә рәвештә вәкаләтле вәкилнең паспорты яки шәхесен раслаучы башка документ күчермәсе, шулай ук вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе теркәлә.

2.9.Өйдә белем алучыны азык-төлек җыелмасы белән тәэмин итү, өйдә белем алучыга азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру турында карарларда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

карарның датасы һәм номеры;

өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) гаризасының реквизитлары, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы -булган очракта), өйдә белем алучының сыйныфы,

өйдә белем алучы түләүсез ике тапкыр туклану белән тәэмин ителгән вакыт аралыгы;

ике тапкыр түләүсез туклану формасы: азык-төлек җыелмасы яки акчалата компенсация;

мәгариф учреждениесе җитәкчесенең имзасы.

2.10.Мәгариф учреждениесе җитәкчесе:

өйдә белем алучының ата-анасына (законлы вәкиленә) азык-төлек җыелмасының составы һәм бирү тәртибе турында (ике тапкыр түләүсез туклану азык-төлек җыелмасы формасында бирелгән очракта) хәбәр итә;

өйдә белем алучының ата-анасыннан (законлы вәкиленнән) гариза кабул итү, өйдә белем алучыны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү өчен кирәкле документлар белән эшләү өчен җаваплы затны билгели (алга таба-җаваплы зат),

өйдә белем алучының ата-анасына (законлы вәкиленә) азык-төлек җыелмасы бирү буенча мәгариф учреждениесе ашханәсе хезмәткәрләре арасыннан җаваплы затны билгели (ике тапкыр түләүсез туклану азык-төлек җыелмасы формасында бирелгән очракта).

Җаваплы зат:

өйдә белем алучының ата-анасыннан (законлы вәкиленнән) әлеге Тәртипнең 2.6 пунктларында күрсәтелгән документларны кабул итә, аларны мәгариф учреждениесенең локаль актына ярашлы рәвештә теркәүне һәм карауны тәэмин итә;

кирәк булганда, өйдә белем алучының ата-анасына (законлы вәкиленә) өйдә белем алучыга түләүсез ике тапкыр туклану турында гариза бирү тәртибе һәм вакыты турында консультация бирә;

әлеге тәртиптә, мәгариф учреждениесенең локаль актында каралган башка бурычларны башкара.

2.11.Азык-төлек җыелмасын бирү мәгариф учреждениесенең локаль акты белән билгеләнгән календарь графикка ярашлы рәвештә, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта буенча тәкъдим ителгән формада мәгариф учреждениесе ашханәсе хезмәткәрләре арасыннан җаваплы зат тарафыннан җыелма ведомость буенча башкарыла.

2.12. Өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) мәгариф учреждениесенең календарь графигында күрсәтелгән датада һәм вакытта азык-төлек җыелмасын алу өчен мәгариф учреждениесенә мөрәҗәгать итә. Мөрәҗәгать

иткәндә, өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) шәхесен раслаучы документын күрсәтә. Билгеләнгән датада һәм вакытта азык-төлек җыелмасын алу мөмкинлеге булмаган очракта, өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) бу хакта мәгариф учреждениесенә шәхсән үзе яки азык-төлек җыелмасын алу датасын һәм вакытын хәбәр иткән мәгариф учреждениесенең электрон почта адресына электрон формада, әмма календарь графигында күрсәтелгән азык-төлек җыелмасын бирүнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча, язма рәвештә хәбәр итә.

Өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан азык-төлек җыелмасын алу факты җыелма ведомостьта шәхси имза белән раслана.

Өйдә белем алучының ата - анасы (законлы вәкиле) азык-төлек җыелмасын алудан баш тартканда (алга таба-алудан баш тарту) яки билгеләнгән вакытта азык-төлек җыелмасын алмаган очракта, мәгариф учреждениесе ашханәсе хезмәткәрләре арасыннан җаваплы зат, үз вазыйфаи бурычларын мәгариф учреждениесендә укучыларны тукландыруны оештыру һәм тәэмин итү белән бәйле булмаган эшчәнлек алып баручы кимендә ике хезмәткәрне җәлеп итеп, азык-төлек җыелмасын алудан баш тарту (алмау) турында акт төзи.

Актта күрсәтелә:

актның төзелгән көне, вакыты, урыны,

өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) азык-төлек җыелмасын алу өчен чакырылган дата, вакыт,

азык-төлек җыелмасын алмау (алудан баш тарту) сәбәбе;

өйдә белем алучының ата - анасының (законлы вәкиле) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда),

актны төзүгә җәлеп ителгән мәгариф учреждениесе хезмәткәрләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы- булганда), аларның имзалары;

мәгариф учреждениесе ашханәсендә эшләүче хезмәткәрләр арасыннан җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы- булганда), аның имзасы.

Азык-төлек җыелмасын алудан баш тарту турында акт җаваплы затка тапшырыла.

Азык-төлек җыелмасын алудан баш тартканда, тиз бозыла торган ашамлыклар мәгариф учреждениесенең башка укучыларын тукландыруны оештыру өчен кулланa. Башка ашамлыклар мәгариф учреждениесенең календарь графигы буенча азык-төлек җыелмасы бирелгән соңгы көннән алып җиде календарь көн узгач, мәгариф учреждениесенең башка укучыларын тукландыруны оештыру өчен куллана.

Белем алучының туклануын оештыруда кулланылмаган ашамлыклар билгеле бер вакыт эчендә закон нигезендә исәптән чыгарылырга тиеш.

Өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) азык-төлек җыелмасын алудан баш тарткан очракта, азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру каралмый.

2.13. Өйдә белем алучыга ике тапкыр түләүсез туклануны туктату өчен нигезләр:

белем алу мөнәсәбәтләрен туктату;

ике тапкыр түләүсез туклану хокукын югалту.

2.14. Өйдә белем алучыга ике тапкыр түләүсез туклану бирү әлеге Тәртипнең 2.13 пунктында санап үтелгән нигезләр буенча мәгариф учреждениесенең ике тапкыр түләүсез туклану бирүне туктату турында боерык акты кабул ителгән көннән туктатыла.

2.15. Акчалата компенсация мәгариф оешмасында көндезге формада белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшь категориясендәге инвалид балалар өчен уку көнендә бер укучының ике тапкыр түләүсез туклануының расланган бәясеннән һәм уку көннәре санынннан чыгып бирелә.

2.16. Акчалата компенсация түләү ай саен, ул бирелә торган айдан соң 10 числодан да соңга калмыйча, өйдә белем алучының ата-анасының (законлы вәкиленең) Россия кредит оешмасында ачылган «Мир» түләү системасындагы исәп-хисап счетына күчерелә.

Өйдә белем алучының ата - анасының (законлы вәкиле) банк реквизитлары яки фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда) үзгәргән очракта, өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) бу хакта актуаль мәгълүмат биреп, күрсәтелгән мәгълүматларны үзгәртү турында мәгариф учреждениесенә шәхсән үзе яки мәгариф учреждениесенең электрон почтасына электрон формада җибәрү юлы белән 10 эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

2.17. Өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) күрсәткән исәп-хисап счетына акчалата компенсация түләүне туктату өчен нигезләр:

акчалата компенсация күчерелгән өйдә белем алучының ата-анасының (законлы вәкилнең) ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе яки хокукы чикләнү (опекунның яки попечительнең хокукларын һәм бурычларын туктату);

акчалата компенсация күчерелгән өйдә белем алучының ата-анасын (законлы вәкилен) суд тарафыннан билгесез югалган яки үлгән дип игълан ителгән итеп тану;

акчалата компенсация күчерелгән өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) үлү;

акчалата компенсация күчерелгән өйдә белем алучының ата-анасын (законлы вәкилен) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки чикләнгән хокукка сәләтле дип тану.

Әлеге пунктның икенче-бишенче абзацларында күрсәтелгән шартлар килеп чыккан очракта, акчалата компенсация алучы яки өйдә белем алучының башка атасы яисә анасы (законлы вәкиле) мәгариф учреждениесенә мондый шартлар туганнан соң биш календарь көн эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

Акчалата компенсация түләү мәгариф учреждениесенә әлеге пунктның икенче-бишенче абзацларында күрсәтелгән хәлләр турында хәбәр кергән көннән алып өч эш көне эчендә мәгариф учреждениесе тарафыннан чыгарылган боерык акты нигезендә туктатыла.

Әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән боерык акты чыкканнан соң җиде эш көне эчендә мәгариф учреждениесе өйдә белем алучының яшәү урыны буенча акчалата компенсация түләүне туктатып тору һәм азык-төлек җыелмасын бирүне яңадан башлау турында, акчалата компенсация түләүне яңадан башлау мөмкинлеген күрсәтеп, хәбәр җибәрә.

Акчалата компенсация түләүне яңадан башлау өйдә белем алучының башка атасы яки анасы (законлы вәкиле) тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә өйдә белем алучыга ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алмаштыру турында гаризаны бирү юлы белән башкарыла.

2.18.Өйдә белем алучының ата-анасына (законлы вәкилләренә) артык түләнгән акчалата компенсация суммасы гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә өйдә белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан мәгариф оешмасының шәхси счетына кайтарылырга тиеш.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
04 август 2023 ел, №671
карарына 1 нче кушымта

форма

______________________________ җитәкчесенә
(мәгариф оешмасы исеме)

_____________________________________
(балигъ булган укучының яисә ата-ананың
(законлы вәкил фамилиясе, исеме, атасының
исеме (соңгысы - булган очракта)(тулысынча)

_________________________________________
адресы буенча яшәүче
Паспорт сериясе_________ номеры__________
бирелгән ________ бирү датасы_____________

Муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан оештырылган өйдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән яисә инвалид балага
ике тапкыр түләүсез туклану бирү турында
гариза

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7, 7.1, 7.2 өлешләре нигезендә
__________________________________________________________________________
(белем бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)
___________ вакытка ____ сыйныф укучысына азык-төлек җыелмасы формасында ике тапкыр түләүсез туклану бирүне сорыйм.

____________________
(имза)

____________________
(дата)

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
04 август 2023 ел, №671
карарына 2 нче кушымта
Форма

_____________________ җитәкчесенә
(мәгариф оешмасы исеме)

___________________________________
(балигъ булган укучының яисә ата-ананың
(законлы вәкил фамилиясе, исеме, атасының
исеме (соңгысы - булган очракта)(тулысынча)

___________________________________
адрес буенча яшәүче
Паспорт сериясе_________ номеры__________
бирелгән ________ бирү датасы_____________

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмасы тарафыннан өйдә белем алучы инвалид бала һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыга ике тапкыр түләүсез туклануны
акчалата компенсация белән алмаштыру турында
гариза

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7, 7.1, 7.2 өлешләре нигезендә

_____________________________________________________
(белем алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)
___________ вакытка ____ сыйныф укучысына азык-төлек җыелмасы формасында ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыруны сорыйм.

_____________________
(имза)

_____________________
(дата)

Акчалата компенсацияне түбәндәге исәп-хисап счетына күчерүегезне үтенәм:
№ _______________________________________________________
Банк ____________________________________ БИК ______________________
ИНН ___________________________________
КПП __________________________________
__________________________________________________
(имза)
(дата)

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
04 август 2023 ел, №671
карарына 3 нче кушымта

Форма

Раслыйм Директор

______ (ай, ел) өчен азык-төлек җыелмасы алган өйдә белем алучыларның җыелма ведомосте

| № | Сыйныф | ФИАи | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәү һәм күләм казанышы) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Продуктның аталышы (үлчәнеше һәм күләмен күрсәтеп) | Имза | ФИАи (ата-ана, опекун, законлы вәкил) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | | | | | | | | | |

Азык-төлекне бирү өчен җаваплы ______________________ ____________
(ФИАи) (имза)

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
04 август 2023 ел, № 671
карарына 4 нче кушымта

Раслыйм Директор

________( ай, ел) өчен ике тапкыр түләүсез туклану бәясеннән акчалата компенсация алган өйдә белем алучыларның җыелма ведомосте

| № | Сыйныф | ФИАи | Акчалата компенсация күләме |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | |

Баш хисапчы____________________________________________
(ФИАи)